Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге составына керүче Балчыклы торак пунктында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елның 28 ноябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлегенең Балчыклы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Шәңгәлче авыл җирлеге Балчыклы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертергә. Әлеге сумманың 50% ы күләмендә 2 төркем инвалидлар түли.
2. Алынган акчаларны Балчыклы торак пунктын су белән тәэмин итүне оештыруга юнәлдерү.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шәңгәлче авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Сәлимов

«Совет Шингальчинского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан» ИНН 1630003235 ОГРН 1041619007715